СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 18, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 18 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)94-2-37, факс (84366)94-2-37. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Апаз авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 22 » ноябрь 2018 ел** **№ 131**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советының 2014 елның 2 маендагы 70-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турындагы Нигезләмәдә.

1) 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1 Үзара салым акчаларын җыю тәртибе башкарма комитет карары белән билгеләнә».

2) 5.2-5.4 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы, Апаз авылы, Совет ур., 19 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Хәсәншәех авылы, Космонавтлар ур., 20 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Пөшәңгәр авылы Чапаев ур., 42А йорты, Чапаев ур., 33 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Миржәм авылы, Н.Сафин ур., 36 йорт.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Садиков